Безнен белән бер дулкында бул!

Март, 2025

# Чишмә башы

**Җир йөзендә тынычлык, дуслык,мәрхәмәтлелек,гаделлек булсын!**

## 8 Марта!

**Кадерле хатын-кызлар - әниләр,әбиләр, апалар, сеңелләр! Сезне чын күңелдән 8 Март бәйрәме белән котлыйбыз. Сезгә иң изге теләкләр телибез, якыннарыгызның игелеген күреп яшәргә насыйп итсен. Бу бәйрәм сезгә тормыш яме, яшәү көче өстәсен. Бәхет нурында коенып, назга күмелеп, сөеп-сөелеп яшәгез.**

**Бәйрәм белән!**

### Тарих битләренә күз салсак...

Беренче тапкыр 1901 елның 8 мартында Америка хуҗабикәләре Чикаго урамнарына кастрюльләр һәм тазлар күтәреп чыга. Мондый үзенчәлекле ысул белән алар җәмгыять һәм хакимият игътибарын үзләренә җәлеп итәргә тели.

Чарада катнашучылар сәяси хокукларның тигезләнүен, үзләренә карата хөрмәт, производствода эшләү һәм армиядә хезмәт итү мөмкинлеген таләп иттеләр. Җиде елдан соң бу таләпләр дәүләт күләмендә кабатлана.
Шуннан соң АКШта хатын-кызлар көне игълан ителә.

Халыкара хатын-кызлар көне Алман коммунисткасы Клара Цеткин исеме белән дә бәйле. Ул хатын-кыз реформатор дип санала. Ул 1910 елда Халыкара хатын-кызлар конференциясендә бөтен дөньяда эшләүче хатын-кызлар бердәмлеге көнен гамәлгә кую тәкъдимен чыгара.

Россиядә хатын-кызлар көнен беренче тапкыр Петербургта 1913 елның 2 мартында билгеләп үтәләр.

Россиядә хатын-кызлар көне рәсми рәвештә 2002 елда РФ Дәүләт бәйрәмнәре исемлегенә кертелде.



### БӘЙРӘМ ҖИТТЕ!

Хатын-кыз — тормыш бизәге,
Март җилләредәй назлый.
Сез бит — гаилә учагы,
Сездән башка эш бармый.
Сүндерми саклый аналар
Гаиләсенең учагын.
Йөрәк җылысын бирә ул,
Теләп яхшы буласын.
Күр, кояш ничек елмая!
Өстәп язның җылысын.
Тели ул хатын-кызларга:

Бәйрәм күнелле узсын!
Күңел күтәрелеп китсен
Бәйрәм котлавын алып,
Сөеп-сөелеп яшәгез,
Яратып-яратылып.
Бүгенге котлаулар сезнең
Йөрәккә дәрт өстәсен.
Сәламәт булып яшәүне
Ходаем насыйп итсен!

Фәймә ЗӘЙНУЛЛИНА.



# Туган ягымда март- матур !

## Март аена халык сынамышлары

**Мартта күк күкрәсә, салкыннар көтегез.**
**Күк күкрәмичә генә яшен күрсәгез, җәй салкын булыр.**
**Март яңгырлы булса, гөмбәле җәйгә ишарә.**
**Мартта суык һәм коры булса, икмәк уңар.**
**Мартта боз сөңгеләре озын булса, яз озак килер.**
**Мартта томаннар еш төшсә, яңгырлы җәйгә.**
**Март ахырында карның тиз эрүе һәм суларның тиз китүе дә яңгырлы җәй билгесе.**

## Март аенда

**Кар дип җиргә басасың,**

**Суга кереп батасың.**

**Чыксын инде умырзая**

**Кар астында ятмасын.**

**Мартлар җитсә, яз җитә,**

**Бураннары булса да,**

**Песи чыккан урамга**

**Аяклары туңса да.**


**Әминә Бикчәнтәева**

Март ае бездә озак заманнар яңа елның беренче ае булып йөргән. Кояш календаре буенча ул төннең язгы тигезлеге вакыты –21 мартка туры килгән. Бу көнне кояш Хәмәл (Кузы) йолдызлыгына кергәнгә, айның үзенә дә “хәмәл” исеме биргәннәр. Татарлар аны тагын “нәүрүз ае” дип тә йөрткәннәр.
Условие

Яңа елның беренче көнендә татарларда да аграр эчтәлекле төрле ритуаллар , аерым алганда, өйдән-өйгә йөреп нәүрүз әйтү, бүләк җыю йоласы башкарылган.
Хәзерге календарь буенча беренче марттан яз фасылы башланып китсә дә, кыш әле бирешергә теләми. Күп кенә сынамышларда мартның “холкы” үзен сиздергән.

- Хәмәлдә әмәлеңне корытырмын
- Март, мартның көне шарт
- Март ае - шарт ае

Алдагы һава торышын, игенчелек хәлләрен билгеләү өчен халык календаренда март аеның ничек килүе әһәмиятле саналган. Мәсәлән,



Март берендә аяз –

Аяз булыр бөтен яз.

Беренче мартта урамда су күренсә, язгы ташуда су күп килер

# *Ял итәбез бергәләп*

**Шууны кара квадраттан башлыйлар. Аңлатмаларны укыганда, карандаш ярдәмендә вертикаль, горизонталь һәм диагональ буенча юл салыгыз. Төп шарт: бернинди сүз дә «ватылырга» тиеш түгел, ягъни кинәт кенә уз юнәлешен үзгәртергә тиеш. Бер сүзнең соңгы хәрефе икенчесе өчен беренче хәреф булып хезмәт итә. Уен ахырында кырда ниндидер бизәк яки фигура барлыкка киләчәк. Җаваплар-сүзләрнең татарча тәрҗемәсе.**

| | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ә | а | ы | р | ә | о | о | к | ы | м | к | р | с | к | м | а |
| л | д | г | а | ш | м | в | п | р | а | б | и | а | е | ш | р |
| л | ы | с | к | ш | е | т | е | л | р | е | б | с | к | о | л |
| б | а | ч | а | я | а | к | а | ә | г | и | ч | а | ә | т | а |
| р | а | к | ә | н | ө | г | х | я | а | и | н | а | р | ү | в |
| е | ы | к | а | е | з | л | ө | т | к | а | к | у | ң | о | ы |
| а | в | к | р | у | а | к | к | и | т | у | о | ә | а | г | к |
| а | р | е | к | к | о | ө | н | н | р | к | ч | с | ы | л | ы |
| я | с | у | е | у | к | ә | а | ә | ы | е | а | е | л | а | н |
| ә | г | ш | а | р | т | т | а | н | а | к | ы | ә | к | р | р |

1. Летучая мышь
2. Палка
3. Внезапно
4. Сытый
5. Щавель
6. Обгорелое полено
7. Пищевод
8. Бахрома
9. Вечер
10. Лыжи
11. Хвоя
12. Стража
13. Крыло
14. Торжество
15. Голодный
16. Висок
17. Этика
18. Соболь
19. Условие

## ***Табышмакка җавап тап***

**Агачта ун чыпчык иде,**
**Берсен кудык, таш атып.**
**Ничә чыпчык калды анда,**
**Кара әле баш ватып.**

**Бер имәндә унөч ботак,**
**Ботак саен өчәр алма,**
**Бу имәндә ничә алма?**

**Теше кырык — тешләми.**
**Кулдан китсә эшләми...**

**Түбәсендә тарагы,**
**Койрыгында урагы,**
**Тәпиендә сәнәге,**
**Шул ни булыр, йә әле?**

## ***Аермаларны тап***



## ***Бәйрәм табынына тәмле торт***

**Бу торт өчен бары тик 4 ингредиент кына кирәк:**
**- Шәһәр каймагы 18% (600 г) - Шикәр комы 100 г (0,5 ст) - Желе 3 кап (тиз әзерләнә торган; 3 төрле төстә булса бигрәк тә әйбәт) - Желатин 20 г Әзерләү: 1. Коры желега (50 г) 1 стакан (200 мл) су салып болгатабыз һәм 3 сәгатькә суыткычка куябыз (һәр пачканы шулай аерым савытларга ясыйбыз). 2. Желатинга (20 г) 1 стакан (200 мл) кайнап суынган су салып болгатабыз һәм "куперер өчен" беразга калдырып торабыз. 3. Күпергән желатинны су ваннасында эретәбез 4. Аерым савытка каймакны салабыз, шикәр комы өстибез һәм эретелгән желатинны кушып болгатабыз .**
**5. Әзер төрле төстәге желеларны савытында килеш кенә пычак белән кискәләп, каймаклы кушылмага салабыз. Болгатабыз .**

**6. Әзер массаны силикон савытка салып (андый савытыгыз булмаса, башка посудага целлофан пакет җәеп) суыткычка "туңарга" куябыз.**

**Чәй янына бик тәмле ризык!**



## ***Теленңне йотарлык салат***

**Тәмле салат өчен: йомырка, ысланган тавык ите, яңа өзелгән кыяр, корейча кишер, каты сыр, майонез.**
**1 кат угычтан уылган пешкән йомыркан, майонез;**
**2 кат туралган ысланган тавык ите ; майонез;**
**3 кат туралган кыяр;**
**4 кат корейча кишер;**
**5 кат угычтан уылган сыр..**
**Майонезны ничә кат ягасын үзегез хәл итегез.**
**Тиз генә ясап сыйлана торган салат әзер!**

